**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 сентябрь № 608

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче, 2015 ел, 7 август, 574 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $27^1$ пункт өстәргә:

«$27^1$. Татарстан Республикасының балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектларында урнашкан һәм законнар белән билгеләнгән уылдык чәчү кишәрлекләре һәм кыш чыгу чокырлары чикләрендә уылдык чәчү чорында җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрнең барлык төрләрен үткәрү тыела.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков